**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТУЙМЕТКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108
ул.Школьная, дом 4, с.Туйметкино, 423108
тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90.Tuy.Cmn.2@tatar.ru

# КАРАР

«01» сентябрь 2020 №15

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты тарафыннан
махсус инвестицион контрактлар
төзү тәртибен раслау турында

2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законның 16 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән районы прокурорының 2020 елның 19 августындагы 721-р номерлы «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законны бозуларны бетерү хакында» күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан 1 номерлы кушымта нигезендә махсус инвестицион контрактлар төзү тәртибе.

1.2. 2 номерлы кушымта нигезендә махсус инвестицион контракт төзү турында инвестор гаризасы формасы.

1.3. Махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия эшчәнлеген формалаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе.

1.4. Махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү комиссиясе составы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Туймәт авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Кәримов А.Б.

1 кушымта
Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 01 сентябрендәге
15 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестицион контрактлар төзү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестицион контрактлар төзүнең әлеге тәртибе (алга таба Тәртип), Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы катнашында төзелә торган махсус инвестицион контрактлардан тыш, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестицион контрактлар төзү механизмын билгели.

2. Махсус инвестицион контрактны Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге исеменнән (алга таба – Туймәт авыл җирлеге) Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет), үз көче белән яисә башка затларны җәлеп итеп, махсус инвестицион контрактта каралган вакытта Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә яңа сәнәгать производствосын төзү, йә модернизацияләү, һәм (яки) үзләштерү бурычын үз өстенә ала торган юридик зат яисә индивидуаль эшкуар белән төзи (алга таба - инвестор, җәлеп ителгән зат, инвестицион проект).

Махсус инвестицион контракт Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларының максатчан күрсәткечләренә һәм индикаторларына ирешү бурычларын хәл итү һәм (яки) ирешү максатларында төзелә, аның кысаларында инвестицион проектлар гамәлгә ашырыла.

3. Махсус инвестицион контракт инвестицион проектның 5 елга, ләкин 10 елдан да артмаган инвестиция проектының бизнес-планы нигезендә проект операцион табышына инвестицион проектның чыгу вакытына тигез срокта төзелә.

4. Махсус инвестицион контракт төзү өчен инвестор Башкарма комитетка карар белән расланган форма буенча гариза бирә (2 номерлы кушымта), кушымта белән:

а) инвестицион проектка инвестицияләр кертүне раслый торган документларның (кредит шартнамәсе яки инвестиция проектын финанслау белән башлангыч кредит шартнамәсе яисә җәлеп ителә торган инвестицияләр күләмен раслый торган башка документлар) һәм махсус инвестицион контрактның вакыты тәмамланганчы саклау һәм (яки) инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында кимендә 10 яңа эш урыны булдыру турында язма гарантия йөкләмәсенең билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләре;

б) инвестор махсус инвестицион контрактка кертергә тәкъдим иткән муниципаль хокукый актларда каралган чаралар арасыннан сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне стимуллаштыру чараларының тәкъдим ителә торган исемлеге;

в) инвесторның һәм (яки) җәлеп ителгән затның (аны җәлеп итү очрагында) тәкъдим ителә торган йөкләмәләр исемлеге;

г) белешмәләр:

- махсус инвестицион контрактны үтәү барышында төзелә яки модернизацияләнә һәм (яки) үзләштерелә торган сәнәгать продукциясенең характеристикалары турында;

- инвестицион проект чаралары исемлеге турында;

- инвестицион проектка инвестицияләр күләме турында;

-инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында ирешергә планлаштырылган нәтиҗәләр (күрсәткечләр) турында (еллык һәм йомгаклау күрсәткечләре), шул исәптән түбәндәгеләрне кертеп:

- җитештерелгән һәм реализацияләнгән продукция күләме (акчалата чагылышта) (ел саен календарь ел ахырына һәм махсус инвестицион контракт вакыты тәмамлануга);

- махсус инвестицион контракт вакыты тәмамланганнан соң түләүгә планлаштырылган салымнар күләме;

- махсус инвестицион контракт срогы тәмамлануга чыгарыла торган сәнәгать продукциясе бәясендә кулланыла торган чит ил материаллары һәм компонентлары (җиһазлары) бәясенең өлеше;

- инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында булдырыла торган эш урыннары саны;

инвестор тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрне үтәүне характерлаучы башка күрсәткечләр.

Җәлеп ителгән затның махсус инвестицион контрактны төзүдә катнашуы очрагында, әлеге пунктта күрсәтелгән гариза шулай ук җәлеп ителгән зат тарафыннан да имзаланырга тиеш.

5. Сәнәгать продукциясен җитештерүе төзелә яисә модернизацияләнә торган махсус инвестицион контракт төзү өчен, инвестор әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар белән тапшырыла торган гариза составында сәнәгать җитештерүен булдыруны яки модернизацияләүне һәм яңа эш урыннарын булдыруны, сәнәгый продукция эшләп чыгаруның булдырылган (модернизацияләнгән) куәтләрендә үзләштерүне һәм инвестиция характерындагы түбәндәге чыгымнарны мәҗбүри рәвештә гамәлгә ашыруны раслый торган документларны тапшыра:

а) яңа җитештерү егәрлекләрен булдыру өчен җир кишәрлекләрен сатып алу яки озак вакытка арендага алу (инвестицион проект гамәлгә ашырыла торган җир участогы инвестор яки җәлеп ителгән затлар милкендә булган очраклардан тыш);

б) проект документларын эшләүгә;

в) җитештерү биналарын һәм корылмаларын төзү яки реконструкцияләү өчен;

г) төп чараларны сатып алу, кору, төзү, китерү, консервациядән чыгару һәм модернизацияләүгә (инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында сатып алына торган җиһазларның минималь өлеше модернизацияләнә торган һәм (яки) консервациядән чыгарыла торган җиһаз бәясенең кимендә 25 процентын тәшкил итә), шул исәптән таможня пошлиналары һәм таможня җыемнары, шулай ук төзелеш-монтаж һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләренә.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган раслаучы документлар булып инвестицион проектның бизнес-планы, инвестицион килешүнең (килешүләрнең) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында башлангыч шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе тора, алар инвестицион проектны гамәлгә ашыруда өченче затларның катнашу тәртибен билгели (булганда).

7. Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары булмаган сәнәгать продукциясенә кертелгән сәнәгать продукциясен җитештерүне үзләштерү бара торган махсус инвестицион контрактны төзү өчен, инвестор әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар белән тапшырыла торган гариза составында инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары булмаган сәнәгать продукциясен җитештерүне үзләштерелүен раслаучы документларны һәм инвестицион проектны гамәлгә ашыру турында инвестицион килешү (килешүләр) яисә башлангыч шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе (булганда) тапшыра.

8. Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 4-8 пунктларында күрсәтелгән документлар кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча аларны, инвестор гаризасы һәм әлеге Тәртипнең 4-7 пунктларына бирелгән документларның туры килүе турында Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы имзалаган башлангыч бәяләмә белән, махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссиягә (алга таба - комиссия) карау өчен җибәрә.

Бәяләмәне әзерләү тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

9. Карар белән расланган Махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмә нигезендә эш итүче комиссия инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә әзерли.

10. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән бәяләмәне әзерләгәндә, комиссия әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән инвестор һәм (яки) җәлеп ителгән зат йөкләмәләре исемлегенә, инвестор тәкъдим иткән инвестицион проект характеристикаларына үзгәрешләр кертергә хокуклы түгел.
11. Комиссия Башкарма комитетка әлеге Тәртипнең 4-7 пунктларында күрсәтелгән документлар кергән көннән алып 60 эш көненнән дә соңга калмыйча Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгына бәяләмә җибәрә, анда күрсәтелә:

а) инвестор һәм җәлеп ителгән затның исеме (аны җәлеп иткән очракта);

б) яңа сәнәгать җитештерүен булдыру һәм (яки) үзләштерү буенча инвестицион проект исеме;

в) инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка (аны җәлеп иткән очракта) карата гамәлгә ашырыла торган кызыксындыру чаралары исемлеге;

г) инвестор һәм җәлеп ителгән зат йөкләмәләре исемлеге (аны җәлеп иткән очракта);

д) махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу вакыты;

и) инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында ирешелергә тиешле нәтиҗәләр һәм әлеге нәтиҗәләрне үлчәү күрсәткечләре (ел саен һәм йомгаклау күрсәткечләре);

к) җитештерүе махсус инвестицион контрактны үтәү барышында җитештерелә яки модернизацияләнә һәм (яки) үзләштерелә торган сәнәгать продукциясенең характеристикалары;

л) инвестицион проект чаралары исемлеге;

м) инвестицион проектка инвестицияләр күләме;

н) инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия карары.

12. Комиссия түбәндәге очракларда махсус инвестицион контракт төзи алмау мөмкинлеге турында карарны үз эченә алган бәяләмә җибәрә:

а) инвестицион проект әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга туры килми;

б) инвестор тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар әлеге Тәртипнең 4-8 пунктларына туры килми;

в) инвестор һәм (яки) җәлеп ителгән затка карата тәкъдим ителгән инвестор гаризасында күрсәтелгән кызыксындыру чараларының берсе дә муниципаль хокукый актларга туры килми.

14. Комиссия бәяләмәсе Башкарма комитет тарафыннан алынганнан соң 10 эш көне эчендә махсус инвестицион контракт төзүдә катнашучы затларга җибәрелә.

Махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге турында карарны үз эченә алган бәяләмәне җибәргән очракта, Башкарма комитет шундый бәяләмә белән бер үк вакытта инвесторга һәм җәлеп ителгән затка (аны җәлеп иткән очракта), комиссиянең күрсәтелгән бәяләмәсен исәпкә алып, инвестор һәм җәлеп ителгән зат (аны җәлеп иткән очракта) йөкләмәләре исемлеген үз эченә алган махсус инвестицион контракт проектын җибәрә.

15. Инвестор һәм җәлеп ителгән зат (аны җәлеп иткән очракта) махсус инвестицион контракт проекты алынганнан соң 10 эш көне эчендә Башкарма комитетка имзаланган махсус инвестицион контрактны, йә язма рәвештә төзелгән инвестор яки җәлеп ителгән затның (аны җәлеп иткән очракта) махсус инвестицион контрактны имзалаудан баш тартуын, йә каршылыклар беркетмәсен (бәяләмәдә булган махсус инвестицион контракт шартларына кагылмаган мәсьәләләр буенча) җибәрә.

16. Каршылыклар протоколы алынганнан соң 10 эш көне дәвамында Башкарма комитет шундый каршылыкларны җайга салу, махсус инвестицион контрактка имза кую яки инвестор яки җәлеп ителгән затның махсус инвестицион контрактка имза куюдан баш тартуын алу өчен инвестор яки җәлеп ителгән зат белән (аны җәлеп иткән очракта) сөйләшүләр үткәрә.

17. Башкарма комитет инвесторга һәм җәлеп ителгән затка (аны җәлеп иткән очракта) махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге турында карарны үз эченә

алган бәяләмәне, һәм инвестор һәм җәлеп ителгән зат (аны җәлеп иткән очракта) тарафыннан имзаланган махсус инвестицион контракт проектын җибәргәннән соң 20 эш көне эчендә махсус инвестицион контрактны, яки каршылыклар протоколын, яки махсус инвестицион контрактны имзалаудан баш тарту алмаган очракта инвестор һәм җәлеп ителгән зат (аны җәлеп иткән очракта) махсус инвестицион контрактны имзалаудан баш тарткан дип санала.

18. Туймәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы инвестор һәм җәлеп ителгән зат тарафыннан (аны җәлеп иткән очракта) имзаланган махсус инвестицион контракт алынганнан соң 10 эш көне дәвамында махсус инвестицион контрактка имза куя.

19. Махсус инвестицион контрактның барлык катнашучылары тарафыннан имзаланган нөсхәләре Башкарма комитет тарафыннан махсус инвестицион контрактта катнашучыларга тапшырыла.

2 кушымта
Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 01 сентябрендәге
15 номерлы карарына

Махсус инвестицион контракт төзү турында гариза

Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитеты махсус инвестицион контракт төзү тәртибе (алга таба - тәртип) нигезендә,

_______________________________________________________________________

(инвесторның тулы исеме)

ОГРН___________________________________________________________________
ИНН____________________________________________________________________
КПП____________________________________________________________________
Теркәлү адресы:______________________________________________________
Почта адресы: _______________________________________________________
әлеге гаризага кушымтада ________________________________________________
(махсус инвестицион контракт предметына карап, кушымтаның 1 нче, 2 нче, 3 нче варианты күрсәтелә)
күрсәтелгән шартларда аның белән махсус инвестицион контракт төзүне сорый, ул аның аерылгысыз өлеше булып тора.
Махсус инвестицион контрактны үтәүгә җәлеп ителә

,_________________________________________________________________
(инвестор махсус инвестицион контрактны үтәү өчен махсус инвестицион контрактны имзалауда катнашачак башка затны җәлеп иткән очракта, аның тулы исеме күрсәтелә), ул булып тора

________________________________________________________

(инвесторга карата җәлеп ителә торган затның нәрсә булуы күрсәтелә: бүлендек, җәмгыятькә бәйле, яисә инвестицион проектта катнашу өчен әлеге затны җәлеп итүнең башка нигезе күрсәтелә)
инвесторга карата, бу раслана ,__________________________
(гаризага теркәлә торган, җәлеп ителә торган затның бүлендек/бәйле булуын раслый яисә инвестицион проектта катнашу өчен затны җәлеп итүнең башка нигезен раслый торган документның реквизитлары күрсәтелә)
һәм әлеге гаризага кушымтада күрсәтелгән йөкләмәләрне үз өстенә ала.

Әлеге белән раслыйм:

1) каршы _________________________________________________________
(инвестор һәм җәлеп ителгән затның (аны җәлеп иткән очракта) исеме күрсәтелә)
бетерү процедурасы (юридик зат өчен) үткәрелми, арбитраж судының (юридик затны, индивидуаль эшкуарны) банкрот дип тану һәм конкурс производствосын ачу турында карары юк, аның (аларның) эшчәнлеге Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә туктатылмаган;

2) соңгы тәмамланган хисап чоры өчен бухгалтерлык хисаплылыгы мәгълүматлары буенча инвестор активларының баланс бәясе тәшкил итә ______________________________ сум;

3) узган календарь елында теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга яисә бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча инвесторның бурычы соңгы тәмамланган хисап чоры өчен бухгалтерлык хисаплылыгы мәгълүматлары буенча активларның баланс бәясенең _______ процентыннан артмый;

4) узган календарь ел өчен җәлеп ителгән затның (аны җәлеп иткән очракта) теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга яисә бюджеттан тыш дәүләт фондларына күчерелгән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары соңгы тәмамланган хисап чорында бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары буенча активларның баланс бәясенең _______ процентыннан артмый.

Аффилированный затлар дип хәбәр итәм ___________________________

(инвестор исеме күрсәтелә)

булып торалар ___________________________________________________________,

(Россия Федерациясе Граждан кодексының 53.2 статьясы нигезендә билгеләнә торган инвесторның барлык аффилированный затлары санап үтелә), ә аффилированный затлар ____________________________________________

(җәлеп ителгән затның исеме күрсәтелә (аны җәлеп иткән очракта)

булып торалар__________________________________________________________

(Россия Федерациясе Граждан кодексының 53.2 статьясы нигезендә билгеләнә торган инвесторның барлык аффилированный затлары саналып үтә),

Әлеге белән раслыйм, әлеге гариза нигезендә махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге турында махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия тарафыннан карар кабул ителгән очракта (инвестор исеме күрсәтелә)

әлеге гаризага һәм 2015 елның 16 июлендәге 708 номерлы «Сәнәгатьнең аерым тармаклары өчен махсус инвестицион контрактлар турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган махсус инвестицион контрактның типлаштырылган формасына туры килә торган шартларда махсус инвестицион контрактка имза куярга әзер.

Әлеге гариза буенча контактлы зат булып тора:_______________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә өчен телефон һәм электрон почта адресы күрсәтелә)

Кушымта: (гаризага кушып бирелә торган документлар санап үтелә).

Оешма җитәкчесе

Әлеге белән раслыйм, _______________________________

(җәлеп ителгән затның исеме күрсәтелә)

әлеге гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда бәян ителгән шартларда махсус инвестицион контрактны төзү һәм үтәүдә катнашуга риза.

Оешма - җәлеп ителгән зат
җитәкчесе

(имза) (имза расшифровкасы)

КУШЫМТА
Махсус инвестицион
контракт төзү турында гаризага

I. Махсус инвестицион контракт вакыты - __________________ (ел).
(инвестор тәкъдим иткән инвестицион контракт вакыты күрсәтелә, ул тәртипнең 4 пункты нигезендә исәпләнә)
II. Инвестор йөкләмәләре:
2.1. Махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу срогы дәвамында инвестицион проект гамәлгә ашырыла ________________________________________________________
(нәрсә тормышка ашырылачак дип күрсәтелә - яңа төзү яки модернизацияләү)
сәнәгать җитештерүенең ________________________________________________________,
(сәнәгать җитештерүенең исеме һәм адресы күрсәтелә)
кушымта итеп бирелә торган бизнес-план нигезендә һәм әлеге кушымтаның 2.4 пунктында күрсәтелгән сәнәгать продукциясен җитештерү буенча технологик һәм җитештерү операцияләрен сәнәгать производствосында башкаруны оештыру, кушымта итеп бирелә торган мондый операцияләрне башкару графигы нигезендә.
2.2. Инвестицион проектның киләсе чараларын үтәүне тәэмин итәргә:______________________________________________________________________
_________________________________________________________________;
(бизнес-планда күрсәтелгән инвестицион проектның төп чаралары санап үтелә)
һәм инвестицион характердагы киләсе чыгымнарны тотырга:

| П/п | Чыгымның исеме | Махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу чоры өчен чыгым күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Яңа җитештерү егәрлекләрен булдыру өчен җир кишәрлекләрен сатып алу яки озак вакытка арендалау чыгымнары | |
| 2. | Проект документациясен төзүгә чыгымнар | |
| 3. | Җитештерү биналарын һәм корылмаларын төзүгә яки реконструкцияләүгә чыгымнар | |
| 4. | Җиһазлар сатып алуга, коруга, җитештерүгә, китерүгә, консервациядән чыгаруга һәм модернизацияләүгә чыгымнар, шул исәптән: | |
| 4.1. | җиһазларны сатып алуга, коруга, ясауга | |
| 4.2. | таможня пошлиналары һәм таможня җыемнары | |
| 4.3. | төзелеш-монтаж эшләре (җиһазларга карата) һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләре | |

2.3. Инвестицион проектка инвестицияләр кертергә гомуми күләмдә______________________________________________________________
______________________________________________________________
(инвестицияләрнең гомуми күләме күрсәтелә сумнарда (сан һәм сүз белән)
Инвестицияләр чыганагы булып тора:
______________________________________________________________________
_________________________________________________________________,
(инвестицияләр чыганагы тасвирламасы: үз чаралары, заем/кредит чаралары, инвестиция эшчәнлеге турындагы закон нигезендә инвестицион проектны гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган инвестицион килешүдә катнашучыларның чаралары, башка чыганаклар),

ул раслана_____________________________________________________.
(инвестицияләрнең һәр чыганагы буенча инвестицияләр кертү мөмкинлеген раслаучы документ(лар) күрсәтелә, мәсәлән, кредит килешүе яки инвестиция проектын финанслау белән башлангыч кредит килешүе)
2.4. Киләсе сәнәгать продукциясен (алга таба - продукция) җитештерүне үзләштерүне тәэмин итәргә:

| П/п | Продукция исеме | Гомумроссия продукция классификаторы нигезендә продукция коды | Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган продукциянең салымнары булу/булмау турында белешмәләр <*> | Продукцияне җитештерү башланырга тиешле хисап чоры | Продукцияне җитештерү күләме (сумнарда) һәр хисап чорының ахырына | Махсус инвестицион контракт гамәлдә булу тәмамланган вакытка продукция җитештерү күләме (сумнарда)срогы | Продукциянең характеристикалары <**> |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |

2.5. Инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында хисап чорларында түбәндәге күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә (хисап чоры тигез )
(инвестор тәкъдим иткән хисап чоры күрсәтелә, ул бер календарь елдан да ким булырга тиеш түгел.)
һәм махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу срогы тәмамлануга кадәр <***>:

| П/п | Күрсәткечнең исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе беренче хисап чоры ахырына | Күрсәткечнең мәгънәсе икенче хисап чоры ахырына | Күрсәткечнең мәгънәсе n-хисап чоры ахырына <****> | Махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу срогы ахырына күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Җитештерелгән продукция күләме (мең сум) | | | | |
| 2. | Сатылган продукция күләме (мең сум) | | | | |
| 3. | Түләүгә планлаштырыла торган салымнар күләме (мең сум), шул исәптән: | Күрсәтелми | Күрсәтелми | Күрсәтелми | |
| 3.1 | федераль салымнар | Күрсәтелми | Күрсәтелми | Күрсәтелми | |
| 3.2 | региональ салымнар | Күрсәтелми | Күрсәтелми | Күрсәтелми | |
| 3.3 | җирле салымнар | Күрсәтелми | Күрсәтелми | Күрсәтелми | |
| 4. | Сәнәгать продукциясе бәясендә чит ил | Күрсәтелми | Күрсәтелми | Күрсәтелми | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | производствосы өчен кулланыла торган материалларның һәм компонентларының (җиһазларының) бәясе өлеше (%) | | | | |
| 5. | Булдырыла торган эш урыннары саны (шт.) | | | | |
| 6. | <****> | | | | |

2.6. ____________________________________________________________
(инвестор махсус инвестицион контракт нигезендә үз өстенә алырга әзер булган башка йөкләмәләр күрсәтелә)
III. Җәлеп ителгән зат үз өстенә түбәндәге йөкләмәләрне ала <******>:
________________________________________________________________________
__________________________________________________________
(инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында җәлеп ителгән зат йөкләмәләре санап үтелә)
IV. Махсус инвестицион контрактка кертү өчен стимуллаштыру чараларының тәкъдим ителгән исемлеге:

| П/п | Кызыксындыру чаралары исеме | Стимуллаштыру чараларын куллануны күздә тоткан норматив хокукый акт яисә муниципаль хокукый акт исеме | Кызыксындыру чарасы кулланыла торган зат (инвестор яки җәлеп ителгән зат) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |

V. Махсус инвестицион контрактка кертү өчен инвестор тарафыннан тәкъдим ителгән өстәмә шартлар:________________________________
_________________________________________________________________.
(инвестор теләге буенча махсус инвестицион контрактның өстәмә шартлары күрсәтелә, аларны инвестор махсус инвестицион контрактка кертергә тәкъдим итә)
<*> Инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында үзләштерелә торган сәнәгать продукциясенең аналогы булган Россия Федерациясендә җитештерелә торган сәнәгать продукциясе булмавы күрсәтелгән очракта, сәнәгать продукциясенең Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары булмаган сәнәгать продукциясенә каравын раслаучы документ реквизитларына сылтама китерелә, гаризага күрсәтелгән документның кушымтасы беләи.
<**> Сәнәгать продукциясенең түбәндәге характеристикалары күрсәтелә: функциональ билгеләнеше яки башкарыла торган функцияләр исемлеге, куллану өлкәсе, сыйфат характеристикалары (гарантия срогы, яраклылык вакыты яки хезмәт итү срогы, ышанычлылык, энергия сыйдырышлылыгы, экологичносте, клиник нәтиҗәлелеге (медицина эшләнмәләре һәм дару препаратлары өчен), физик, химик, механик, органолептик һәм продукциянең бары тик тышкы кыяфәтенә карамаган башка үзлекләре.
<***> Әгәр дә инвестор нинди дә булса хисап чорында яисә махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң нинди дә булса күрсәткечкә ирешү буенча йөкләмәләрне үз өстенә алырга җыенмый икән, ул тиешле графада күрсәткечнең мәгънәсен "0" дип күрсәтә.
<****> Хисап чорларында ирешелгән күрсәткечләр күрсәтелгән баганалар саны махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу вакыты дәвамында хисап чорлары санына тигез булырга тиеш.
<*****> Инвестор теләге буенча инвестицион проектны тормышка ашыруның башка нәтиҗәләре (күрсәткечләре) күрсәтелә.

<******> Әлеге бүлек махсус инвестицион контракт төзүдә җәлеп ителгән зат катнашмаган очракта тутырылмый.

3 кушымта
Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 01 сентябрендәге
15 номерлы карарына

Махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) эшчәнлеген формалаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте актлары, муниципаль хокукый актлар белән эш итә.

3. Комиссия рәисе, аның урынбасары һәм комиссия әгъзалары составында комиссия төзелә.

4. Комиссия составына керә:

а) комиссия рәисе – Туймәт авыл җирлеге башлыгы;

б) комиссия рәисе урынбасары – Туймәт авыл җирлеге башлыгы урынбасары;

в) комиссиянең 1 әгъзасы - ________________________ (килешү буенча).

г) комиссиянең 2 әгъзасы - Туймәт авыл җирлеге Советы депутатлары (килешү буенча).

5. Комиссия составы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән раслана.

6. Комиссия эшенә аның һәр конкрет утырышында катнашу өчен рәисе карары буенча тавыш бирү хокукы белән кызыксынучы җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләре (алга таба - тавыш бирү хокукы белән катнашучылар) җәлеп ителергә мөмкин:

а) сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектлары һәм кысаларында махсус инвестицион контракт төзелә торган шул ук тармакның сәнәгать өлкәсендә эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы оешмалары вәкилләре (5 әгъза), - инвестицион проект кысаларында җитештереләчәк сәнәгать продукциясенең Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары юклыгы турында документ булмаган сәнәгый продукция җитештерүне төзүне яисә модернизацияләүне һәм (яки) үзләштерүне күздә тоткан махсус инвестицион контракт төзү очрагында;

7. Комиссия рәисе:

а) комиссия эшен оештыра;

б) комиссия утырышларында мәсьәләләрне карау исемлеген, срокларын һәм тәртибен билгели;

в) комиссия эшен планлаштыруны оештыра;

г) җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләрдә комиссияне тәкъдим итә;

д) комиссиянең һәр конкрет утырышында катнашу өчен тавыш бирү хокукы булган катнашучылар исемлеген раслый.

8. Комиссия рәисе булмау сәбәпле, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

9. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия хокуклы:

а) аның компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тиешле җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә, алардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүмат алырга;

б) аналитик һәм эксперт эшләрен гамәлгә ашыру өчен тавыш бирүдә һәм комиссия карарларын кабул итүдә катнашмый торган экспертларны - фәнни оешмалар вәкилләрен һәм инженер-техник профиль белгечләрен түләүсез җәлеп итү.

10. Комиссия утырышларын чакыруны һәм үткәрүне вәкаләтле орган елга кимендә ике тапкыр (махсус инвестицион контрактлар төзү турында гаризалар булганда) тәэмин итә.

11. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, карарлар кабул итү өчен хокуклы дип санала.

12. Комиссия утырышы турында хәбәрнамә һәм кирәкле материаллар комиссия рәисе кушуы буенча аның әгъзаларына һәм тавыш бирү хокукы белән катнашучыларына комиссия утырышы уздырылган көнгә кадәр бер айдан да соңга калмыйча вәкаләтле орган тарафыннан җибәрелә.

13. Комиссия әгъзалары һәм тавыш хокукы белән катнашучылар комиссия утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

14. Комиссия карары, булмаган комиссия әгъзаларының һәм тавыш бирү хокукы белән катнашучыларның язма фикерләрен исәпкә алып, комиссия әгъзаларының һәм тавыш бирү хокукы белән катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Комиссия әгъзалары һәм тавыш бирү хокукы белән катнашучылар, Россия Федерациясе законнары нигезендә, инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка карата конкрет махсус инвестицион контрактка карата мәсьәләләрне караганда аффилированносте булу очрагында, үз кандидатурасын тәкъдим итүдән читләштерүне (самоотвод) белдерергә тиеш.

16. Материалларны карау һәм фикер алышу нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия бәяләмәсен әзерләү турында карар кабул ителә.

17. Инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия бәяләмәсендә түбәндәге белешмәләр бар:

а) инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка (аны җәлеп иткән очракта) карата гамәлгә ашырыла торган кызыксындыру чаралары исемлеге;

б) инвестор һәм җәлеп ителгән зат (аны җәлеп иткән очракта) йөкләмәләре исемлеге;

в) махсус инвестицион контрактның гамәлдә булу вакыты;

г) инвестицион проектны гамәлгә ашыру барышында ирешелергә тиешле нәтиҗәләр һәм күрсәтелгән нәтиҗәләрне үлчи торган күрсәткечләр (ел саен һәм йомгаклау күрсәткечләре);

д) махсус инвестицион контрактны үтәү барышында җитештерелә яки модернизацияләнә торган һәм (яки) үзләштерелә торган сәнәгать продукциясенең характеристикалары;

е) инвестицион проект чаралары исемлеге;

ж) инвестицион проектка инвестицияләр күләме;

з) инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестицион контракт төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия карары.

18. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия утырышында катнашучы барлык комиссия әгъзалары (тавыш бирү хокукы белән катнашучылар) тарафыннан имзалана. Булмаган комиссия әгъзалары (тавыш бирү хокукы белән катнашучылар) тарафыннан бирелгән язма фикерләр беркетмәгә кушыла.

19. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик һәм матди-техник яктан тәэмин итү Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

4 кушымта
Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 01 сентябрендәге
15 номерлы карарына

Махсус инвестицион контрактлар төзү мөмкинлеген бәяләү комиссиясе составы

1. Туймәт авыл җирлеге башлыгы –

2. Туймәт авыл җирлеге башлыгы урынбасары –

3. _______________

4. Туймәт авыл җирлеге депутаты -

5. Туймәт авыл җирлеге депутаты -